*Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!*

ISSN 0136-7110

# Чаян



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ АВГУСТ * 2021 * КАЗАН

8




Илдар НӘФИЕВ

Рашат НИЗАМИ

## "ХИКМӘТЛЕ" ТЕЛЕВИЗОР!

Кичләрен мин телевизор карыйм –
Анда хикмәт, анда тамаша...
Ярым шәрә текә җырчылардан,
Һәм шоулардан күзләр камаша!

Зур түрәләр, житди министрлар
"Отчёт" бирә: бездә үсеш, дип;
Йөгәнләдек инфляцияне,
Тормышыбыз алга китеш, дип.

Россиядә ике тормыш бара,
Күреп була: җете күз белән.
Телевизор көн дә "сыйлый" безне
Әйбәт хәлләр, ялган сүз белән.

Россиядә ике төрле тормыш –
Чынбарлыкта ...Зәңгәр Экранда...
Ике якны чагыштырып кара,
Ни хикмәтләр генә юк анда!

Экраннарда зәңгәр төсләр белән
Алсу төсләр балкый – чуарлык...
Тормыш дигән дөньялыкта исә
Ачыдан да ачы чынбарлык:

Тарифлар һәм кибет бәяләре
Көннән-көнгә өскә сикерә.
Ярлы мескен кабар ризык эзли,
Туклыгыннан байлар кикерә...

Күз яшьләрен йотып елый әнә
Ятимнәр һәм сукбай балалар.
...Капкорсаклар торбалардан куып
Газ, нефеттән маемланалар.

Җитәр, күңел!
Мондый моң-зарларны
Лутчы өзик шушы урында.
Кайчан, кайчан сөйләшербез икән
Матур тормыш,
Чып-чын дөреслекләр турында?!.

Алмаз ХӘМЗИН


* * *

Чын дөреслек – синдә, миндә,
Гади халык телендә.
Туры әйтеп сөйләшү юк –
Менә шулай бүгенгә...

Чын дөреслек – тирәндәрәк,
Шыта алмый – басылган.
Ялган белән әвәләнгән,
Аерылган асылдан.

Чын дөреслек хәрам белән
Алышынган, буталган.
Хәләл яшәү рәхәтлеге
Күпләрдә онытылган!..

Валерий ТАРАСЕНКО





## ШОМБАЙ *болай диде...*

Хөрмәтле Чаян! Һәр яңа көн безгә юллардан күңелсез хәбәрләр китерә: ике башсызы машиналары белән бәрелешеп һәлак булган, телефонына ябышкан кызый «зебра» аша чыгып баручы гаиләне харап иткән, ә бер исерек егет гаишникны бәрдертеп киткән... Юлларда хәл кискенләшә бара, зыян күрүчеләр һәм һәлак булучылар саны арта. Нишләргә икәнен беркем дә белми, ахры...

**А. ДӘУЛӘТШИНА**

КАЗАН

Шомбай ага укучыбызның хатын укып чыкты.

**– Безнең яткан полицейскийларыбызга торырга һәм тәртип урнаштырырга вакыттыр, –** диде аксакалыбыз.

Рөстәм ЗАРИПОВ

## ВАЗГЫЯТЬ

Елга бер язучы – ул бик күп бит,
Йөз елга бер туса, була таман....
Язучы саналган "колхозчылар",
Бертуктаусыз үрчи тора һаман...

Гади халык рәхәтләнеп укый
Дан Казанмаганның романнарын,
Исемле, титуллы лауреатлар
Сагышлана, учлап мандатларын...

Һәммәсенең уртак калыплары,
Күпчелек тәмамлаган татфилфак,
Артист булалмаганнары шактыйлар,
Башларда түбәтәй яки калфак...

Беркем укымагач, китапларын,
Милләт уянмый дип акланалар,
Асрамадагы гәҗит-журналда
Үзара макташып, якланалар...

Уңышы шашындыра Дансызның,
Ташланалар аңа көтү белән.
Иҗатына җитми, диләр алар,
Тимер авызлык һәм каеш йөгән...

...Язучылар колхозында кара кайгы,
300 әгъза чирек гасыр тудырганны
Тираж, чит илләргә чыгу җәһәтеннән
Шәлперәйткән Яхинаның бер романы...

Елга бер язучы – ул бик күп бит...
Чын язучы берәү-икәү генә бездә,
Лауреат, титуллы, исемлеләр,
Мандатлылар, әдип санала тик сүздә...

Александр ЛЕВИТИН







Сергей АНДРИАНОВ

# Ахмаклыктан прививка

Бик озак аның турында безнең колак итен ашаганнан соң, ниһаять, вакцинация дигәннәре башланып китте. Бирәүләр укол кадатырга аның кирәклеген чын күңеленнән аңлап бара, ә икенчеләре исә эш бирүченең камчысыннан куркып юл тота. Ләкин шул ук вакытта ковидка каршы кагыйдәләрне әйләнеп узарга теләп, мошенниклар кулына эләгүчеләр дә бик күп. Теңкәгә тиеп беткән пандемиянең таләпләре көн саен үзгәреп тора, ә моның артыннан закон әһелләре генә түгел, ә төрле аферистлар да күзәтеп тора.

Иң кечкенә табыш QR-кодлар һәм медотвод, ягъни прививка ясатмаска хокук бирүче белешмә сатучылар кулына керә. Аның бәясе өч меңнән башланып китә. Вакцинация сертификатлары белән сәүдә итүчеләрнең табышы күбрәк – документның төренә карап, 10 меңнән 40 меңгә кадәр. Бу очракта клиенттан аның шәхси мәгълүматларын алалар, ә аннан соң аларның счётларыннан еш кына зур суммалар юкка чыккалый.

Әйтергә кирәк, Мәскәү мэрының прививка үткән гражданнар арасында автомобильләр уйнату һәм вакцинацияләнгән пенсионерларга матди ярдәм күрсәтү турындагы тәкъдимен мошенниклар хуплап каршы алдылар. Һәм шунда ук үз чараларын тәкъдим иттеләр. Аларның барысы да зурдан – ясалган прививка өчен 15 меңгә кадәр, автомобильләре дә затлырак. Бары тик тиешле юлга банк картасының мәгълүматларын гына кертергә кирәк. Ә моннан соң, әлбәттә, беркем дә акчаны да, кыйммәтле машинаны да күрми.

Мошенникларның әле тагын бер төре бар – ак халатлы кешеләр. Гамәл болай тормышка ашырыла. Поликлиникада кешене карыйлар, анкета тутыралар, аннан соң язма ризалык алалар. Ә менә вакцина үзе клиентның организмына түгел, ә чүп савытына китә. Рәсми документлар бар, сертификат компьютерда, буш флакон – менә ул, ә отчётларда вакцинация үткәннәрнең саны үсә тора.

Әмма хокук сакчылары да йоклап ятмый, әлбәттә. Санкт-Петербургта, мәсәлән, ялган тест нәтиҗәләре белән сәүдә итүчене тоткарлаганнар. Ростовта 1 нче номерлы поликлиника хезмәткәрләрен бер аферист белән берлектә "Авито" аша бөтен теләгәннәргә вакцинациясез генә вакцинация сертификатлары тәкъдим итүдә гаеплиләр. Саратовта да бер фельдшер шундый ук эш белән шөгыльләнгән. Ә безнең Казанда консультация-диагностика үзәгендә эшләүче 21 яшьлек кыз вакцинация сертификатлары сатып яткан. Ялган кәгазьләрнең бәясен 2 дән 4 меңгә кадәр билгеләгән. Намуссыз медик шулай итеп 200 мең сум эшләргә өлгергән.

Ялган документлар әзерләүчеләр һәм аларның клиентлары өчен җәза да уйлап чыгарылган: әзерләү һәм сату – рәшәткә артында ике ел, саклау һәм файдалану – бер елга кадәр. Әгәр инде ялган прививка иясе массакүләм авыру китереп чыгарса – ике миллионга кадәр штраф йә өч елга кадәр ирек белән хушлашу. Маска кимәгән өчен алынган штрафлар белән чагыштырып булмый инде моны!

Фәнни тикшерүләр күрсәтүенчә, вакцинацияне ярты ел саен кабатлау зарур. Шомарган мошенниклар өчен бу әйбәт хәбәр – димәк, кесә тутырырга мөмкинлекләр сакланачак. Тик шулай да "кәгазь прививка" нәтиҗәсен бирер – ул көтелмәгән нәрсәләргә китереп, ахмаклыктан прививкага әйләнер дип ышанасы килә.

**Людмила САФИУЛЛИНА**


















• • •

– Ни өчен мин физиканы яратам? Аның законнарын берәү дә боза алмый, хәтта акча биреп тә.

• • •

Бу җәйдә дәүләт оешмаларына мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итүдә салкынлык сизелә иде.

• • •

– Әни, син нигә мине дискотекага җибәрмисең?

– Дискотека юньлегә китерми ул: мин дә әтиең белән шунда таныштым.

• • •

Депутатларны кагылгысызлык хокукыннан мәхрүм иткән очракта, кайберләрендә тотып булмаслык иммунитет барлыкка килә.

• • •

Бер кило кишер һәм ике чөгендер сатып алдым. Менә хәзер фараз кылып утырам – мин кем: урта хәллеме, әллә бай россиялеме?

• • •

– Безнең илдә миллионлаган кеше футбол уйный белми, бары тик җыелма команда уенчылары гына зур акчага моны эшли ала...

• • •

– Минем хәзер йөзләренең аскы өлешен беркайчан да күрмәгән танышларым барлыкка килде.

• • •

Айга бер тапкырдан артык борщ ашау – салым инспекциясенең чираттан тыш тикшерүенә сәбәп булырга мөмкин һәм әле чит ил агенты итеп чутлану реестрына кертеп куярга да күп сорап тормаслар.

• • •

– Гафу итегез, ләкин мин сезне битлексез килеш банкка кертә алмыйм!

– Ә соң әнә теге? Ул бит битлексез һәм ыштансыз да?!

– Ул – башка хәл. Клиент ипотекасын түләде һәм китеп бара.

Валерий АНТОНОВ

# Ярдәм итәрбез...

– Әлү! Бу идарә итүче компаниямe! Ярдәм итегез!..

– Ә "исәнмесез" кайда?

– Нинди "исәнмесез" ди ул?! Бу алтынчы йорттан шалтыраталар. Безне су баса!

– Яхшы хәбәр. Димәк, сездә су шәп килә...

– Безгә тизрәк сантехник кирәк! Суны ябарга.

– Башта сезгә суны ябарга. Аннан соң җәй уртасында җылыны өзегез, диячәксез. Бәлки, телефонын да өзеп куяргадыр – көне-төне шалтыратып, элемтәгә керә алмыйсыз бит... Илдәге бардак менә шулай башлана да инде!

– Нәрсә башымны катырасыз? Подвалдан ташкын бәреп тора, тиздән тәрәзә аша ага башлаячак. Слесарь җибәрегез хәзер үк! Сезнең белән сәгать буе сөйләшәм, ичмасам, ник бер нәрсә кузгалсын. Ай!..

– Ни булды?

– Кузгалды! Диван кузгалды. Күршеләр ягына агып бара...

– Менә, ә сез кузалмый, дигән буласыз... Җырда да шулай бит – "ага сулар гел шулай"...

– Нинди җыр ул тагын! Слесарь бармы, юкмы сездә?

– Слесарь бар ул. Штатный расписание буенча. Тик ул йөзә белми шул...

– Ә сез кем? Әйтегез! Мин сезнең өстән жалоба язачакмын!

– Мин — катлаулы ситуацияләрне хәл итү буенча диспетчер-психолог-менеджер. Әле ярты ставкага электрик та. Ут белән барысы да тәртиптәме? Янамы?

– Бездә инде диңгездәге кебек – чайкалабыз! Күңел болгана башлады хәтта! Ә сезгә барыбер!!!

– Гафу итегез, начар ишетелә башлады. Безнең идарәче компания белән элемтәдә каласыгыз килсә, якорь ташлагыз.

– Нәрсә-нәрсә? Голт-голт...

– Ачыграк сөйләшегез, авызыгызга су капкан кебек мыгырдыйсыз. Борчылмагыз, ярдәм итәрбез.

– Нәрсә?! Голт!..

– Искәртәбез: хезмәт күрсәтүне яхшырту максаты белән безнең сөйләшү язып барыла. Хәбәр көтегез... Шешәгә салынган хат алырсыз... Яңа ЖКХ тарифлары белән...



Илдар НӘФИЕВ

## СҮЗ ИЯРӘ – СҮЗ

Кеше 90 процентка судан тора, шуңа күрә күпләр тормышларын үз агышына җибәрәләр.

Кискән юл, гадәттә, иң озыны булып чыга.

Һәр ишәк үзенчә фикер йөртә, ләкин бөтен ишәкләрнең дә бертөрле килеп чыга.

Даһи – ул даһиларча түгел, ә башкача эшләүче.

Чукраклар тизрәк уртак тел таба.

Түбәнне югары дия-дия, үзең түбәнәя барасың..

Бар нәрсә өчен дә түләргә кирәк, әмма беркайчан да артыгын түләргә кирәкми.

Хатын-кыз – ире аның рәсемнәрен генә карарга ярата торган китап ул.

Юрий ТУБОЛЬЦЕВ




Вячеслав ШИЛОВ

Альберт ГАЙСИН

# БУРЫЧЛЫ

Туктаусыз машина йөреп торган трасса кырыендагы юл патруле машинасы янында инспектор Бәйләнчеков белән суд приставы Талапов тора иде. "Бурычлылар" операциясе бара – алимент түләмәүчеләрне, штрафка тартылганнарны һәм башка качып йөрүчеләрне тоталар.

Талапов, үткен карашы белән машина агышына карап торганнан соң, кисәк атылып куйды.

– Күрәсеңме кара микроавтобусны?! – дип кычкырды инспекторга. – Туктат, сизәм безнең клиент!

Бәйләнчеков ашыкмый гына жезлын селкеде. Машина, поворотнигын җемелдәтеп, тормозына басты. Инспектор, аңлашылырлык итеп үзен таныштырганнан соң, документларын сорады. Күз йөртеп алгач, аларны приставка бирде. Тегесе ашыкмый гына бер бармагын төртеп, андагы мәгълүматларны ноутбукка терки башлады.

– Командир, тизрәк кыймылдагыз әле? – дип ашыктырды аны рульдә утыручы. – Вакытым юк...

– Кая чабасыз? – дигән катгый сүз чыкты Бәйләнчеков авызыннан.

– Клиентны илтеп җиткерәсем бар, халык көтә...

– Нинди клиентны? – дип гаҗәпләнде инспектор. – Син кабинада үзең генә түгелме соң?..

– Клиент салонда... Карагыз менә, – ул ишек ачты. Микроавтобус эчендәге кырыйда тикшерүчеләр "Ритуаль хезмәт" дигән язу күрделәр.

– Ә-ә, алай икән! – диде дә каушап куйды Талапов һәм үзен шундук кулга алды. – Шулай да бурычларың бармы-юкмы икәнен тикшерик әле, бер туктагач...

Ярты сәгатьтән соң катафалк үзенең кайгылы юлына кузгалды.

–Ниләр генә булмый безнең хезмәттә... – дип уфтанып алды инспектор.

– Әй-йе-е... – диде Бәйләнчеков аңа кушылып, – Юкка җибәрдек без аны! – дип өстәде.

– Нигә?

– Үлгән кешесен дә тикшерергә кирәк иде мәгълүматлар базасында. Бәлки, ул ЖКХга бурычлары булу сәбәпле, теге дөньяга китәргә уйлагандыр, Аллам сакласын, әле ЮХИДИга да штрафлары булмады микән?..






Александр БРЮХАНОВ

## ҖИҢҮ ГЕНӘ КИРӘК!

Госпиталь ишеге янында борчылуын яшермичә мыеклы бәндә басып тора иде. Ул әледән-әле килеп туктаган машиналарны каршы алып, ярдәмчесенә күрсәтмәләр биреп тора.

Микроавтобустан носилка белән бер егетне чыгардылар.

– Монысын реанимациягә... Кичекмәстән аякка бастырырга!

Кара джиптан тагын берәү сөйрәлеп чыкты.

– Ә моңа тиз генә укол ясарга да, кире илтеп куярга...

Башы бәйләнгән кешене китерделәр.

– Башына операция ясарга кирәк... Платина пластинка куярга... һәм чыгарырга...

Шул вакытта ишек янында култык таягына таянган тагын бер егет пәйда булды.

– Монысына тиз генә протез куярга... һәм тиз генә кире илтергә...


...Соңгы булып зәгыйфь адымнар белән караңгы чырайлы кеше барлыкка килде. Ул каршы алучыга карап алды да, өметсез итеп кулын болгады...

– Монысын психотерапевтка...


һәм тирән сулап куеп, мыеклы бәндә кисеп куйды:

– Миңа – валидол һәм зәңгәр пиджагымны...

Ярты сәгатьтән флаглар болгап кычкыручы җанатарлар әйләндереп алган команда икенче таймны уйнарга китте. Алда үзенең җиңү генә китерә торган зәңгәр пиджагын кигән мыеклы тренер бара иде. Уенчыларның башында бер генә уй – җиңәргә. Бары җиңү генә аларга мул премияләр китерәчәк. Аның хакына егетләр бөтен газапларга түзәргә әзер...







Виктор ФЁДОРОВ рәсемнәре






## СПОРТ ТИРӘЛИ

Россия Спорт комитетының шигаре: хоккейда җиңмәсәк, футболда бәхет елмаер. Футболда барып чыкмаса, Олимпиада бар... һәм шулай календарь буенча!

Анна Курникова ракеткасын кадакка асып куйды. Павел Буре кәшәкәсен чишенү бүлмәсендә калдырган. Ә Данис Зарипов зур хоккейдан китәргә никтер уңайсызлана.

Халыкара футбол федерациясе кара уенчыларга ак судьяларны футбол кырыннан чыгару хокукы бирү каралган кагыйдә кертергә уйлый.

Япониядәге Олимпиадада бөтен Россия, нишләптер, нин-дидер флагсыз һәм гимнсыз җыелма команда өчен җан атты.

Фехтование – коронавирус вакытында иң шәп спорт төре. Син маскада, әгәр берәрсе сиңа метр ярымнан якынрак килә икән, аңа рапира белән кадарга була.

Спортта кем дә җиңә ала, ә син менә анализлар биреп кара.




## АЛДЫНГЫ УНЛЫК

Көтмәгәндә Татарстан иң күп эчүче өлкәләрнең беренче дистәсенә кергән. Бу елның беренче кварталында татарстанлылар 1,62 миллион декалитр спиртлы эчемлекләр сатып алып, ышанычлы алтынчы урын яулаганнар. Беренче урында, гадәттәгечә, Мәскәү тора – анда 6,4 миллион декалитр "бөкләнгән", икенче урында – алты миллионы белән Мәскәү өлкәсе, ә аннан соң тыйнак кына 3,37 миллион декалитр "кабул иткән" Санкт-Петербург атлый. Ә менә Ингушетия исә бу рәтнең койрыгында булып чыккан. Бу республикада яшәүчеләр бары тик 6 мең декалитр эчкәннәр.

## ЮЛЛАР, ЮЛЛАР...

Әлмәт районының алты авылында юллар ремонтлаган компания директорын 1,3 миллион сум урлауда гаеплиләр. Тикшерүчеләр фикеренчә, 2017–2018 елларда бу җитәкче юлларны тиешле таләпләргә туры килмәгән вак таш белән каплаган. Эшне кабул итү актларына имза куйдыртып, ул җирле район хакимияте хезмәткәрләрен төп башына утырткан. Документларда каралган һәм чынлыкта башкарылган эшләрнең аермасыннан калган акчаны үз кесәсенә салган.

## БИЧАРА КОНДЫЗЛАР

Эссе җәй Тукай районының "Росинка" бакчачылыгындагы сусаклагычның саегуына китергән. Бакчаларда сибәргә су җитми башлаган. Бакчачылар бу афәтнең сәбәбен, нишләптер... кондызларда күргәннәр һәм аларга сугыш ачып, аларның буа-корылмаларын вата башлаганнар. Закон буенча су җәнлекләренә зыян китергән өчен зур гына штраф яный, ләкин аңа да карамастан, сусаклагычтагы өч кондыз гаиләсе инде һәлакәт чигенә җиткән.

## ХАТЫНЫННАН ҮЧ АЛГАН

Казанда берәү хатыны белән ызгышкан, һәм аңа ачу итеп яшь кыз белән күңел ачарга булган. Күңеленә хуш килгән чибәркәйне сайлап, аның белән очрашу турында сөйләшенгән. Ләкин көтелгән ләззәтне ала алмаган. Тегесе башта акчаны алдан бирүне сораган, телефоннан, ирне юмалый-юмалый, 228 мең сум күчерергә мәҗбүр иткән. Һәм аннан соң кулына акча төшкән кызның телефоны җавап бирми башлаган.

Дамир МОРТАЗИН

# ИҖАДИ КРИЗИС

"Аһәңсезлек гармониясе" авангард музыкасының фестиваль директоры Тависов тележурналистка интервью бирмәкче булды. Тегесе, сорау бирергә керешмичә үк, тырышып, әйе дигәндәй, башын селкергә кереште.

– Безнең фестивальнең музыкасы рухи инновацияләрнең алдынгы сафында тора. Моның өчен мәнсезлек өеренең башында торучы Саңгыраулинның фамилиясен атау да җитә, – дип горурланып әйтеп куйды Тависов. Үзенең карашын интервью алучы майлы күзле кыздан аермыйча. – Без моңа хәтле яшәп килгән эстетик гореф-гадәтләрдән, хәзерге мәгълүм тамашачы таләпләрен күздә тотып читләштек...

– Ә тамашачы сезнең агымга кушылыр микән соң? – дигәндәй, журналист кыз сак кына башын чайкап алды.

– Сез аны залга карап белә аласыз, ул – тутырук! – дип горур әйтеп куйды Тависов. – Әлбәттә, Роспотребнадзор таләпләрен үтәп...

Тависов тележурналисттан котылырга өлгермәде, аның каршына очып, администратор Бикмуллин килеп басты.

– Шеф, бәла! – коты чыккандай әйтеп башлады сүзен. – Бетте баш, җәнҗал, һәлакәт!

– Нәрсә булган тагын? – дип интегебрәк сорады директор.

– Фестивальне башларга вакыт, ә композитор Саңгыраулин үзенең хәтәр "Томана тавыш" оркестры белән чыгыш ясаудан баш тарта!

– Нигә? – дип гаҗәпләнде Тависов. – Гонорарына риза түгелме?

– Анысы белән каршылык юк – налогсыз кулына тоттырабыз, сөйләшкәнчә...

Саңгыраулин сәхнәдәге рояльнең тәзек түгеллегенә бәйләнә... Расстроен, ди...

– Нәрсә-ә-ә? Нәрсәгә аңа тәзек яңгырашлы рояль? Аның бит музыкасы "дөбер-шатыр" белән тулган...

– Аңламыйм, – дип уфтанды администратор. – Күренекле – андыйларга киреләнү хас... Тәзәтүчене эзлибез эзләвен, ләкин ул иҗади кризиста – махмыр...

– Җир астыннан булса да табып китер! – дип өзеп әйтте сүзен Тависов.

Бикмуллин чыгып сызды, шул вакыт сәхнәдә, алпантилпән килеп, тәзәтүче пәйда булды.

– Бер шешә аракыга ризалыгын бирде, – дип, аның килүе турында доклад бирде Бикмуллин Саңгыраулинга.

Тәзәтүче киреләнеп кенә клавишларга суккалады, рояльнең өске капкачын ачты һәм шунда кереп югалды. Беркавымнан кабат чыкты да түшәмгә карап гел бертөрле телләргә басып, дөбердәтергә тотынды. Залдагылар шаккатып карап тора башладылар, ә фестивальгә килгән музыка тәнкыйтьчеләре, аптырап, чыккан тавышка колак салып, нәрсәдер аңларга тырыштылар.

– Карале, нәрсәдер бар бит монда... – дип пышылдаштылар алар үзара. – Моңарчы булмаган, яңалык һәм гадәти түгел... Нәкъ агымдагыча... Композиторының исеме ничек, нигә ул программада язылмаган... Бу бит фестиваль ачышы...

– Сезнең каршыда – оештыручыларның сюрпризы! – диде ялкынланып, әмма бераз аптырашта калган һәм дә акылына килгән Тависов. – Иртәгә сез аның турында барысын белерсез...

Соңыннан, тәзәтүче, арып-талып рояльне тәртипкә китереп ава-түнә сәхнәдән чыккач, залда башта тыныч кына, ләкин тора-бара көчәйгән алкышлар яңгырады. Тависов "Аһәңсезлек гармониясе"нең ачылышы белән залдагы барлык тамашачыларны һәм берочтан яңа талантның беренче уңышлы дебюты уңаеннан котлады.

Ә "фестиваль ачышы" үзенең иҗади кризисы каршына – өенә таба атлады, әле ул бу вакытта иртәгесен танылган бөек музыкант булып уянасын белми иде.





Александр ШУЛЬПИНОВ






Валерий ТАРАСЕНКО



## БЕР ФИКЕРГӘ – ИКЕ КАРАШ

**Рашат Низами:** Телевизор безне көн саен диярлек ялган океанында коендырырга маташа...

**Алмаз Хәмзин:** Ә без коенмыйбыз!

**Р. Н.:** Җанисәп алдыннан академик Тишковның безнең милли диварга нинди "тишек"ләр тишкәнен гади халык аңлап бетерми бугай?

**А. Х.:** Җитмәсә, үзебезнең арадагы кайберәүләр татарлыгыбызга "ямау" салалар...

**Р. Н.:** Мәңгелек хакыйкать берәү генә – туу һәм үлем.

**А. Х.:** Шикләндергәне дә бар бит әле аның – оҗмах һәм тәмуг.

**Р. Н.:** Яхшылык – кыр чәчәге сыман, ул бездән берни дә сорамый.

**А. Х.:** Ямавлык – буш аракы шешәсе кебек, гел акча таләп итә, әйеме?

**Р. Н.:** "Алтын уртаклык"ны табар өчен рудалар актару кирәк түгел.

**А. Х.:** Шагыйрь булу өчен дә шулай түгелме?

**Р. Н.:** Мин сөйгәнемне сайламадым, миңа аны Аллаһ җибәрде.

**А. Х.:** Бу очракта Аллаһы Тәгаләне гаепле итәргә кирәк түгел иде инде.

**Р. Н.:** Кәфенлектә ни өчен кесә булмый? Чөнки акчаларыңны "теге дөнья"га алып китә алмыйсың...

**А. Х.:** Безгә ул турыда кайгырасы юк. Дөньялыкта без хәерче.

**Р. Н.:** Әй, кешеләр, сак булыгыз – дан кешене бозарга мөмкин!

**А. Х.:** Хәзер денсезләр данлы.

**Р. Н.:** Сөембикә манарасы авыш, дибез. Ә бәлки тарихыбыз кыек торадыр?..

**А. Х.:** Ул авыш булса да – горур әле!!!

**Р. Н.:** Романны язалар, ә шигырьне язмыйлар, ул үзе туа.

**А. Х.:** Синең кебекләре булганда!

**Р. Н.:** Ачу килгәндә, унга кадәр санарга кирәк, диләр...

**А. Х.:** Бу араларда күренмисең, әллә өеңнән чыкмыйча, ачуың килеп, җәмгыятьне сүгеп ятасыңмы әллә, бертуктамый санап.

### УКУЧЫ ШИГЫРЬ ЖИБӘРДЕ

Фирүс ШӘЙМӘРДАНОВ

## АЧУ ЧЫККАЧ

Карантинда утыра-утыра,
Шактый гына көч җыйгач.
Бабай ачуын чыгара –
Бөгеп сындыра агач!



## КАЯ КУЙЫЙК

Ява бәхет, ява маллар –
Пенсия арттыралар.
Баш ватабыз икәүләп,
Һәм йөрибез мукәләп.
Кая куйыйк ул акчаны,
Үлемтеклек букчаны?
Бирә аны әзләп-әзләп,
Безне «яраткан» дәүләт!

## Абау!

### УҢЫШЛЫ ЗАРПЛАТА

Свердловск өлкәсенең Красноуфимск районында «Урал» ЖЧҖ Авыл хуҗалыгы предприятиесе хезмәткәрләренә хезмәт хакын азык-төлек карточкалары белән бирә башлаганнар. Хезмәткәрләр аларны шунда ук «уңыш» дип атаганнар. «Уңышлы акчалар» белән кайбер җирле кибетләрдә азык-төлек кенә сатып алырга була, ә менә коммуналь хезмәтләр, балалар бакчасы яки юл өчен түләү мөмкин түгел. Предприятие башлыгы һәм депутат Владимир Айметов мондый түләү системасы аның башка предприятиесендә инде 15 ел уңышлы эшли, дип ышандырган. Әмма прокуратура карточкаларны Хезмәт кодексы тарафыннан түләү тыелган бурыч распискалары буларак бәяләгән.

### БАШ һӘМ КУЛ ЭШЛӘҮ

Мәскәү укучысы, бер тиен акчасы булмаган килеш, Мәскәүдә фатир сатып алган. Ул бу алыш-бирешне читтән торып башкарган, сатучы компания почтасына барлык кирәкле документларны, шул исәптән, әти-әниләренең Питер банкыннан 18 млн. сумга түләү һәм сатып алу ризалыгын җибәргән. Юристлар исәп-хисап счётына акча кермәвен, ә документлар график программада ясалган икәнлеген аңлаганчы, мәктәп укучысы пропискага кереп, сатып алынган күчемсез милектәге йозакларны алыштырырга, бу адреска яшелчәләрне күпләп сату буенча компания теркәргә, үз фамилиясен алыштырырга һәм торакны сатуга куярга өлгергән. Яшь аферистны фаш итәләр, тик ул бирелергә ашыкмый, ә бөтен нәрсәгә дә электрон документ әйләнешенең мөстәкыйльлеген гаепле дип саный.

### КАРТЛЫК

Чиләбедән пенсионер ханым телефон мошенникларын 500 сумга алдаган. Банк счётында 50 сум акчасы булуга карамастан, ул анда 8 миллион сум барлыгын әйткән. Аферистлар ханымга акчаны икенче счётка күчертергә ашыктыра башлыйлар, тик 70 яшьлек пенсионер үзенең телефонына кергән шалтыратулар түләүле, дип белдерә. Күп вагъдә итүче сөйләшү өзелмәсен өчен, мошенниклар «клиент» счётына 500 сум акча салганнар. Әби шул чакта гына 8 миллионның башка банкта саклануын исенә төшерә, ә мошенниклар кулында нибары илле сум акча гына кала.

### УКРАИНЧА РОБИН ГУД

Украинада судьялар һәм чиновникларны талаган «робингудлар» бандасын тоткарлаганнар. Зыян күрүчеләргә аларның барлык мөлкәтләре дә намуссыз юл белән табылган, шуңа күрә конфискацияләнергә тиеш, дип белдергәннәр. Балалар тренеры җитәкчелегендәге банда шул рәвешле берничә ел дәвамында яшәп килгән. Талаулар намуслы булганмы һәм алынган бөтен әйбер хәерчеләргә бирелгәнме яки бандитлар акчаларны үзләренә тотканнармы икәнлеген суд тикшерә.

Игорь КИЙКО



Илдар НӘФИЕВ



Мирзаһит тормышыннан

## ӨЧЕНЧЕ КАЗ

Иртә таңда Гөлбиби оныгын уята башлады:

– Улым, тор, казлар югалган!

Малай әле уянып та җитмәгән иде, ләкин каршы килеп тормады – ничек инде әбиеңә югалган казларны эзләшми була ди! Башта кошларның яраткан урыннарын йөреп чыктылар: аларның күлләвектә коена торган чокырга төштеләр, Кәҗә тавындагы чирәмлеккә менеп карадылар, камышлыкны әйләнеп чыктылар.

Гөлбиби карчыкны авылдашлары турылыгы һәм эчкерсезлеге өчен яраталар иде, һәм шуңа күрә һәрберсе аңа ярдәм итәргә тырышты. Ниһаять, озак эзләгәннән соң, казларның икесе табылды. Ә өченчесе юк кына бит! Тагын бер кат авылны әйләнеп чыктылар – кошкайның эзе дә юк. Арган-талган әби белән оның урам буйлап өйләренә юл тоттылар.

Үз өе янында аларны Мирзаһит чакырып алды:

– Гөлбиби, – дип эндәште ул сөмсере коелган карчыкка. – Кереп кара әле, әнә, минем абзарда почмакта синең казың түгелме ул? – дип, кошлары ягына төртеп күрсәтте.

– Чынлап та, минеке бугай! – дип шатланды Гөлбиби. Күзенә яшьләр тулып, ул аптырап калган казны эләктереп алды да абзардан чыгып йөгерде.

Мирзаһитның күптәнге дусты Вәли дә шунда иде.

– Ә ул каз чынлап та аныкымы соң? – дип сорады ул шикләнеп. – Алар бөтенесе дә бертөсле ич!

– Әгәр каз үзе каршы килмәгән икән, димәк, мин дөрес эшләгәнмен, – диде Мирзаһит, күз кысып һәм Гөлбиби чыгып киткән капканы ябып куйды.

## ҖҮЛӘРЛӘР

Мирзаһитның олы малае Дамир гаиләсе белән күрше авылда яши, еш кына әтисе янына ярдәм итәргә килә иде. Бергәләшеп печән чабалар, бәрәңге утырталар, абзарны чистарталар. Ә эш беткәч, Дамир мәктәп мәйданчыгына дуслары белән футбол уйнарга йөри иде.

Бер шулай Мирзаһит мәктәп тирәсеннән әйләнеп килергә булды. Улының ничек уйнаганын күрәсе килде аның. Уенның иң кызган вакытында Мирзаһит янында йончыган кыяфәтле Туйбар барлыкка килде. Кулларында – ике тулы сумка.

– Вәт җүләрләр, ә! – диде ул уйнаучыларга карап. – Үзләре олы кешеләр, ә кыланышлары буенча бала-чага кебек. Улың җүнле булмады синең, Мирзаһит...

– Ә нәрсәсе начар соң моның? Футбол уйныйлар, спорт белән шөгыльләнәләр, – дип җавап бирде Мирзаһит, ә Туйбарның сумкасында шешәләр шалтыраганны ишеткәч, сорап куйды. – Ә бүген нинди бәйрәм соң, кордаш?

– Менә, улым янына дуслары килеп төште, бәйрәм итәргә җыенабыз, – дип җавап бирде елмаеп Туйбар.

– Әле ике көн элек кенә кибеттә синең аракы алганыңны күргән идем бит! – диде Мирзаһит.

– Соң ул көнне атна ахырын билгеләгән идек. Ял көннәре тагын нигә кирәк?! – диде Туйбар кәпрәеп һәм мәйданчыкка ымлап дәвам итте, – бу, ичмасам, авыл алдында рисвай булып, җүләрләр кебек туп артыннан чабып йөрү түгел!

Һәм шешәләрен шалтыратып китеп барды...

**Зөлфәт ШАҺИӘХМӘТОВ**




Сергей АНДРИАНОВ

Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

# БӘЛЕШ

Эштә яңа фатир биреләчәген ишеткәч, Ялагаев тынычлыгын югалтты. Йокысы да качты. "Кемгә эләгер икән? Ничек шуны беренче булып алырга?.." Шулай уйланып ятканда хатынын уятырга булды:

– Хатын, йоклыйсыңмы?

– Синең боргаланып ятуыңнан бөтен йокы качты инде. Йә, нәрсә булды, ник борчыласың?

– Борчылмаска... Эштә яңа фатир бирергә тиешләр, кемгә тияр. Шуны уйланып ятам. Кайчанга кадәр бу иске йортта торырбыз? Үзебез үҗәтләнмәсәк, берсе дә китереп бирмәс. Син, карчык, иртәгә иртәрәк тор, камыр куй да үзеңнең фирменный бәлешеңне пешер, яме?

– Анысы ник тагын?

– Күп сорашма, эшлә әйткәнне.

Ире йокыдан торганда өстәлдә, хуш исләр таратып, "фирменный" бәлеш тора иде.

Ялагаев бәлешен күтәреп, эшкә китте. Юл уңай ук җитәкче бүлмәсенә керде.

– Хәерле иртәләр, – дип исәнләште ул аның белән. – Менә, хатын бәлеш пешергән иде, сезгә күчтәнәч итеп алып килдем. Авыз итегез. Бик тәмле. Минем хатын шундый шәп бәлешләр пешерә...

– Кая әле, ашап карыйк, – диде җитәкчесе. – Ай-яй, бигрәк тә тәмле икән шул. Уңгансың хатыныңнан.

– Хатын минем мировой! Тик менә йортыбыз гына иске. Ничә еллар кечкенә фатирда интегәбез.

– Ярар, уйлап карарбыз, – дип җавап кайтарды җитәкче.

Берничә көннән яңа фатир Ялагаевка бирелә икән дигән сүз чыкты. Һәм ул фатирлы булды.

Күпмедер вакыттан соң эштә бакча төзергә җир бирәләр икән дигән сүз кузгалды. Ул вакытка җитәкче алышынган иде. Әмма Ялагаев тагын шул ук "фирменный" бәлешен пешертеп, җитәкчене сыйлады. Әлбәттә, яхшы җир аңа бирелде.

Инде эшендә дә, хезмәттәшләре аны иртән бәлеш белән күрсәләр:

– Әнә, яңа җитәкчене сыйларга китте, тагын нииндидер йомышы бардыр, – дип, көлешәләр иде...

Гомер уза торды, җитәкчеләр бер-бер артлы алышынды. Ялагаев бәлешен ташый торды.

Көннәрнең берендә, тагын яңалык: җитәкче алышынган. Ялагаев бәлешен күтәреп, аның бүлмәсенә килеп керде.

– Исәнмесез, иптәш Йөгәнев! Сезнең белән танышырга кергән идем әле. Бәлешемне дә авыз итәрсез дип, күчтәнәч китердем.

– Ә-ә, иптәш Ялагаев! Узыгыз, узыгыз. Ишеткәнем бар сезнең бәлешләр турында. Бик мактыйлар. Тик менә, кызганычка каршы, минем хатын да бик тәмле пешерә. Шуңа күрә мин аның ризыкларын гына ашыйм шул.

Ялагаев, ни әйтергә белмичә, аптырап калды... Бер-ике көннән аны Йөгәнев бүлмәсенә чакырдылар.

Анда керү белән ул өстәлдә бәлеш күреп, сөенеп куйды. "Бәлеш ташыйсы булмас бугай, үзе дә ачык кеше икән", – дип уйлады Ялагаев.

– Мин сезгә нигә чакыруымны әйтәсем килә, – дип башлады сүзен Йөгәнев. – Сез инде күп еллар монда эшлисез, өлкән кеше. Пенсиядә икәнсез. Хәзер яшьләргә дә урын бирергә кирәктер дип уйлыйм. Шуңа күрә, әйдәгез, бергәләп чәй эчеп алыйк та, гаризагызны язып, лаеклы ялга озатырбыз сезне. Хатыныгыз белән бергәләшеп, парлашып, кухняда бәлешләр пешереп, чәйләр эчеп, күңелле гомер итәрсез дигән теләктә калам.

Ялагаев коелып төште. Ул, ни әйтергә белмичә, җитәкче бүлмәсеннән чыгып китте...




Александр ДЬЯКОВ, 1998 ел.



Сергей ТЮНИН, 2003 ел.




• • •

Бераүнең дә әле "Смешные цены" кибетендә бәяләрдән көлгән кешене күргәне юк.

• • •

Хөрмәтле ирләр, сез хатын-кызларның чәчләреннән үбәргә, сыйпарга, хуш исләреннән ләззәт алырга яратасыз... Ни өчен соң әле бүлеп бирелгән аш тәлинкәсеннән бер чәч тапсагыз, шашып ярсыйсыз?

• • •

– Сезнең балыгыгыз әле генә тотылганмы?

– Әлбәттә. Күреп торасыз бит, балыкчысы айнымаган да.

• • •

Ялсыз-нисез, бертуктаусыз һәм күп итеп эшләргә кирәк. Шуннан соң гына үзеңә иң кыйммәтле антидепрессантлар кулланырга һәм иң шәп психотерапевтка күренеп йөрергә була.

• • •

Әгәр ир кеше хатынына чәчәк алып кайта икән, димәк, сөяркәсе очрашуга килмәгән.

• • •

– Сезнең интернетыгыз тиз эшлиме?

– Бик тиз эшли, хәтта аның өчен түләргә дә җитешә алмыйм...

• • •

– Мин йога белән кызыксына башладым. Һәр кич саен кырын ятам да, икешәр-өчәр сәгать бер ноктага карап, медитация ясыйм.

– Төгәлрәк әйтсәң, кайда?

– Телевизор экранына.

• • •

Һәркайда ришвәтчелек! Тулы вакциналану турында сертификат сатып алдым. Ковид эләктердем, сертификатның ялган булуы ачыкланды. Тулысынча терелүем турында справка сатып алырга кирәк булды. Җинаять эше кузгаттылар. Шуннан соң аннан азат ителү турында белешмә сатып алырга туры килде.

• • •

– Күптән өйләнешкән идегезме?


– Сигез ел элек.

– Бер генә булса да ремонт ясый алдыгызмы?

– Өч күченү һәм ике ремонт!

– Никахыгыз бик нык икән!

Валентин ДУБИНИН




Илдар НӘФИЕВ






## СУСЫЗ ЯШӘҮЧЕЛӘР...

Хөрмәтле редакция! Һәркемгә мәгълүм, кешеләрне һәлакәткә сыра китерми, ә эчәргә суның булмавы. Бу чынбарлык белән күп еллар буе Тукай районы халкы интегә – күп кенә авылларда эчә торган су юк.

Көн үзәгендә торган әлеге мәсьәлә белән җирле хакимият күптән шөгыльләнә, ләкин быелгы көтелмәгән эссе һава торышы хәлне тагын да нык кискенләтте. Шулай да, үткән ел республика җитәкчелегенә мөрәҗәгать иткәннән соң, Кече Шилнә, Олы Шилнә, Илбахты, Белоус авылларына үзәк суүткәргечкә тоташтыру вәгъдәсе бирелгән иде. Хәтта 15 километрның 1,5 ен суздылар да, тик, нигәдер, бу эш туктатылды. Халык, инде бораулап, үз коеларын булдырды, ләкин аннан суыртылган су эчәргә яраксыз икәнлеге беленде – аның составындагы төрле химик матдәләрнең нормасы чамадан артык килеп чыккан.

Халык мәкалендәге "Яткан таш астына су акмый" дигәнгә таянып, авыл кешеләре республикабыз Президентына хат юлламакчы булалар. Бәлки, ул түрәләргә: "Сусыз яшәү – мәгънәсез", – дигән гыйбарәне үзләренә су эчертмичә аңлатыр...

**Тукай районы халкы.**

ТАТАРСТАН

## ЧАРА КҮРҮЧЕЛӘР ЮК

Кадерле "Чаян"! Без яшәгән комплекс йортлары янәшәсендә генә Чулман ярыннан елгага төшәр өчен уңайлы итеп эшләнгән урын бар. Бу төшне яшьләр үз итәргә өлгерделәр – шунда ял итәләр, танышалар, кавышалар, күңел ачалар. Бәйрәмнәре шәбрәк узсын өчен, алдан безнең ишегалдында тукталып сыра эчәләр, нәрсәләрдер тарталар. Әле яңа гына эшләнгән матур балалар мәйданчыгы бар иде үз акчабызга төзелгән – ватып бетерделәр; подъездлардан бушлай бәдрәф ясадылар, стеналарында килбәтсез рәсемнәр; түбәсе – экстремаль селфи салоны ролен үти, ә лифтта – мәхәббәт парлары серләшә. Болардан соң яшәүнең мәгънәсе калмый! Кисәтүләргә бик усал җавап кайтаралар, "еракка" да җибәрергә күп сорамыйлар, куллары ияк астына яки муен тамырына менеп төшәргә дә әзерләр. Подъездга куелган йозак та, видеокамералар да бәйдән ычкынган буйнга тәэсир итми...

Инде интегеп беткән яшәүчеләрнең гомуми җыелышында Башкарма комитеты, "Парус" комплексын койма белән әйләндереп алу турында карар чыгарды. Хәзер эш аздан гына калды – башкарма комитет рәисенең бу хәлне үз күзләре белән күрүе. Ә бу, үзегез аңлыйсыз, эше тыгыз түрәгә мөмкин гамәл түгел...

**"Парус" ТК халкы.**

ЧАЛЛЫ

Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Вячеслав ШИЛОВ




## ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Алганда кешенекен вакытлыча алып торасың, ә биргәндә үзеңнекен бөтенләйгә бирәсең.

Идарә итү белән шөгыльләнүче кешеләр хәтта бергә ял итәргә җыелсалар да, ул очрашулар, гадәттә, бәяләрне күтәрү турындагы карар кабул итү белән тәмамлана.

Әгәр мәсьәләне хәл итү күп киңәшмәләр таләп итә икән, ул киңәшмәләр мәсьәләнең үзеннән әһәмиятлерәк булып китә.

Беркайчан да ахмак белән бәхәскә кермәгез – сезнең арадагы аерманы күрмәүләре мөмкин.

Әгәр товар шәп булса, аны чыгармый башлыйлар.

Һәр начальник акыллы көндәшләр санын түгел, ә үзенә буйсынучы хезмәткәрләр санын арттырырга омтыла.

Кем булдыра – шул эшли.

Кем булдыра алмый – өйрәтә.

Кем өйрәтә алмый – идарә итә.

**(Начальниклар мәҗлесендә язып алынды.)**



*Радик Фәизов – (1931-2011) гади авылда туып, әдәбиятка тормышны төптән өйрәнеп килгән кеше.*

*Кайларда гына һәм кем генә булып эшләми ул: мактәп укытучысы, саклык кассасы инспекторы, двигательләр монтажлаучы слесарь, авиа-ция заводында токарь, паровоз кочегары, машинист ярдәмчесе...*

*Шуңа күрәдер Радик Фәизовның иҗаты бик бай һәм күпкырлы. Ул туган ягында – Арча районы газетасы редакциясендә башта әдәби хезмәткәр, аннары җаваплы сәркатип булып эшли. 1970 елда читтән торып укып Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый.*

*Радик Фәизов – нигездә, хикәяче. Аның эшчеләр, тимер юлчылар тормышыннан алып язылган беренче хикәяләре алтмышынчы еллар башында көндәлек матбугат битләрендә, аннан "Беренче адымнар" исемле кумәк җыентыкта басыла. Ул – "Яшьлек юллары" повесте һәм дүрт хикәя җыентыгы авторы. Р. Фәизов балалар мажаралы һәм фантастик әсәрләр дә яза. Шулай ук аның "Чаян" журналында юмористик һәм сатирик хикәяләре басыла.*

*Әдип – Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Х. Ямашев исемендәге әдәби бүләк иясе, Язучылар берлеге әгъзасы була.*




Исеме Сибгат булса да, аны үзара Йомыкый дип кенә йөрибез. Ник дисәң, чынлап та йомыкый ул. Бервакыт тавышын күтәрмәс. Беркемгә авыр сүз әйтмәс. Борын астында ботка пешереп йөрер шунда.

Без – өйләнмәгән егетләр. Әллә ни аптырап торган юк. Получкадан соң ресторанына да сугылабыз, җыйналып та утырабыз. Ник, акчаны кешедән ким төшерәбезме әллә? Без кемнәрдән ким? Яшьлекнең рәхәтен күреп калыйк. Дөнья кайгысы сул якта торсын әнә... Шулай ич!

Йомыкый гына читтә. Йә кочагы белән китаплар ала, йә авылдагы әти-әнисенә бүләкләр җибәреп азаплана. Үгетли калсаң, авыз эченнән нидер мыгырдый башлый. Ата-ана рәхмәте мең гөнаһтан кичерә, ди бугай. Хан заманындагы бу сүзне каян казып алган диген? Яшьлеген әрәм үткәрә шунда, җүләр.

Ә шулай да бәла аңа килмәде, миңа килде.

Беркөн, получка алып, тулай торакка кайттым. Тумбочкада кәгазь кисәге ята. Язуын укыган идем, кемдер бозлы кулы белән муенымнан кысып алгандай булды: "Фәлән йорт почмагындагы таш астына егерме сум акча саласың. Югыйсә... Милициягә дәшсәң – әҗәлеңне бездән көт! Банда".

Тораташ булдым да калдым. Бу ни әкәмәт тагын? Каян килгән бу заманда бандитлар? Нәкъ менә Америка гангстерлары кебек кыланалар... Нишләргә?

Бүлмәдә китапка багынып утырган Йомыкыйдан башка җан иясе юк иде. Аптырагач, аның янына килдем. Язуны укуга куркып калды, бичара. Күзге яфрак кебек калтырый. Җәлт кенә үз тумбочкасын актарып ташлады. Юк, бандитлар Йомыкыйны җәлләгәннәр...

– Миңа нишләргә хәзер? – дим. – Киңәш бир!

– Ни әйтим мин? – ди. – Теләсәң нишлә. Бәлки, берәрсе шаяргандыр гына... – ди әле.

Бу куян юньле киңәш бирер дисеңме?!

Шаярсалар, акчамны кире бирерләр, шаярмасалар, егерме сумга карап башымнан колак кагар хәлем юк. Илтим дә салыйм. Күргәне-күрмәгәннәре шул булсын...

Әмма бандитларның күргәне ул гына булмады әле. Икенче получкадан соң мин тагын егерме сумга "чакыру билеты" алдым. Өченчесеннән соң тагын... Тәмам изаланды кеше. Акчасы, анда-монда дигәндәй, әллә ни җәл түгел аның. Шул бер-ике рәт ресторан ишегеннән кире борылып китәргә генә туры килде. Әмма менә хурлыгы... Иптәшләргә сөйләргә дә куркам. Милициягә читләтеп кенә үтәм хәзер. Артымнан авызына пычак капкан бандит күзәтеп бара кебек. Юк, болай булса, расчет алып, шәһәрдән үк чыгып ычкынмый булмас.

Дүртенче получканы алып кайтсам, өстәлдә хат ята. Авылдан, әнидән. Бердән, кара тирләрем чыкты. Акча сорый инде! Әле тумбочканы ачкан юк, шулай да анда нинди кәгазь ятканын белеп торам инде... Талыйлар! Хәзер инде уңлап-суллап талыйлар.

Хатны укый башлаган идем, чәчләрем үрә торды. Менә нәрсә язылган иде анда:

"Сөекле улым Камил! Инде бу айда акча салмасаң да ярар. Үзеңә авырлык килмәсен. Җибәргән акчаларыңа үземә шәл, атаңа пима, сеңлең Мөршидәгә күлмәк алдык. Синең ярдәмең ярап куйды. Сиңа тәүфыйк биргән өчен – Аллага..."

Мин артык укый алмадым... Башымны күтәрсәм, каршымда Йомыкый басып тора. Авызы колагыннан узып бара тегенең.

Тып итеп урыныма утырдым, телсез калдым.

Менә сиңа Йомыкый!




Ринат АБЗАЛОВ






Илле яшьлек юбилее уңаеннан Гәрәйгә вертолет бүләк иттеләр. Бик үк яңа булмаса да, әле тагын ун-унбиш ел очарга мөмкинлеге бар икән. Моннысын Гәрәйне туган көне белән котлап шалтыраткан Артем үзе әйтте.

Әфганстанда бергә хезмәт иткән Артем исемле дустының хәзер инде Себердә нефть белән бәйле шәхси эшен көйләп җибәргән эшкуарның шушы шалтыратуыннан соң Гәрәй берара югалып, каушап калды. Чөнки соңгы ун елда аларның бөтенләй хәбәрләшкәннәре юк иде. Дөрес, Армия сафларыннан кайткан елларда Артем аларда өч тапкыр кунак булды. Гәрәйне ул үз абыйсы кебек бик якын итә иде шул. Безнең якларны, бигрәк тә Агыйдел буйларын бик ошатып киткән иде ул. Үзе дә әллә ничә тапкыр дустын Себергә чакырып карады, юл хакын да үзем түлим дигән иде, тик Гәрәй генә бара алмады. Хәер, сәбәпләре булгандыр инде...

Гәрәйнең күңелендә онытылган хатирәләр кабат яңарды, уйлары бәгыренә үтеп калган утлы еллар тирәсендә тирбәлде... Төн узды, көн уртасы җитте. Менә ул ихата тирәсендәге алачыкта печән чабу җайланмасын көйләп ята. Тиздән печәнгә төшәр чак җитә бит. Ул да тирә-күрше фермерлардан калышмаска тырыша. Шунда, зәңгәр күк йөзендә пәйдә булган очкычны күреп эшеннән бүленде. Вертолет авылны бер әйләнде, ике әйләнде дә, бер урында эленеп тора башлады. Ул арада аның кесә телефоны шалтырады. Аннан:

– Гарай, это ты? – дигән ят тавыш яңгырады.

– Да.

– Куда можно посадить вертолет?

– Сейчас, – диде дә Гәрәй, бәрәңге буразнасы буйлап, янәшәдәге кабак бакчасына йөгерде. Аннары тельняшкасын салып болгады. Вертолет әкрен генә кабаклар арасына төшеп утырды. Ике урынлы, түгәрәк шар сыман пыяла кабиналы очкыч, алгарак китеп булса да әйтик – Robinson R22 – чыннан да бик матур иде. Ул арада авыл халкы да җыелып өлгерде, һәммәсенә дә кызык, бигрәк тә балачагаларга. Очучыны кунак итеп, сыйлап чыгарган арада "джунгли" булып күренгән кабак бакчасы тапталып, такыраеп беткән Сабантуй мәйданчыгына охшап калган иде.

...Авыртмас башка тимер тарак булып төшкән бу очкыч аларның төн йокысын качырды. Инде дүртенче атна алар ирле-хатынлы нишләргә соң дигән сорау белән башларын катыралар. Аны файдаланыр өчен генә дә күпме чыгым тотарга кирәк бит. Әйтик, очучыга түләргә, техник хезмәт күрсәтүчегә, ягулык-майлау материалга. Шулай гына булса әле. Әллә сатып җибәрергәме дигән фикергә дә килəләр. Әнә мөслимлеләр "Вамин"нан "мирас" булып калган йөзләгән техниканың бер өлешен (хәтта тәзек булган тракторларны да ) килограммын 1 (бер!) сумнан сатып җибәргәннәр бит әле, ягъни металлоломга тапшырганнар. Дөрес, прокуратура хезмәткәрләре кайбер оештыручы җитәкчеләргә "СИЗО исе" иснәтеп караган кебек.

Гәрәй дә, болай гына, сынап карар өчен генә район газетасына "Килограммы унбиш мең сумнан вертолет сатыла" дигән игълан биреп кайта. Икенче көнне Сарман, Минзәлә, Яр Чаллы якларыннан егермеләп эшмәкәр килеп төшмәсенме, малай? Кәттә очкычта Президент сымаграк итеп очасы килә тегеләрнең. Тапталган кабак бакчасы уртасында кукраеп утырган очкыч тирәли и йөренәләр, көчләрәкләре вертолетның койрыгыннан күтәреп тә карагандай итәләр. Кайберләре телефоннан очкычның оригинал бәяләрен табып, башларын чайкап куялар, ни турындадыр сөйләшеп алалар. Юк, сатып алучы табылмый.

Гәрәйнең хатыны Гүзәл ханымның үзенә дә канатлар үсеп чыккандай була ул көннәрдә, кая басканын белми оча-йөгерә йөри. Ире белән киңәшеп вертолетны шомырт агачлары тирәсенәрәк күчертә, кабак җирен йомшартып яшел үлән чәчеп җибәрә. Ире Сызраньга очучылар әзерләү курсларына укырга киткәч, 100 әр сумнан вертолет янында фотога төшү мөмкинлеген оештыра. Кабинага утырып төшкән өчен исә 500 сум ала. Һәр тиеннең кадерен белә ул. Болар өстенә аның күңелендә тагын бер матур хыял уянып килә. Ул – туризм һәм... Әйе, теләгән кешеләргә авиация хезмәте күрсәтү. Туган авылы өстеннән очамы ул, берәр җиргә ашыгамы... Кече эшмәкәрлекне үстерәбез дип, һаман үгезләр тирәсендә генә кайнашырга димәгән бит, мәсьәләгә югарыданрак та карарга кирәктер дип уйлый...

Кибеткә, мәктәпкә барганда ул инде хәзер Тольяттинең Лада-Гранта машинасына утырмый, җәяү бара. Аның атлап йөрү рәвешенә чаклы үзгәреп киткәнен авылдашлары Гайшә, Рәфигалар да сизә. Берсе-берсе дүртәр-бишәр бүлмәле фатир бәясенә тиң торган "БМВ", "Мерседес" кебек затлы машиналарында элеккеге кебек җилдереп, "выжт" итеп кенә узып китәргә батырчылык итмиләр инде хәзер, тизлекләрен киметеп, баш кагып, исәнләшеп узалар. Чөнки Гүзәлләрнең вертолетлары бар. Быел булмаса, киләсе елга әфлисун төсле кабак бакчаларыннан күтәрелеп оча-кайта йөрүләре көн кебек ачык аларның.

**Мидхәт САДЫЙКОВ**




**САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ**

1923 елдан чыга.

**№ 8 (1909) август 2021**

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЕШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе
«ТАТМЕДИА»
акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре,
Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләре агентлыгы
ярдәмендә оештырылган.
Журнал
Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы,
йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша
язылa алалар.

**Язылу индекслары:**
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның
ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү
хокукына ия.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 02.08.2021 ел.
Тираж – 3374 Заказ Е-2522

**Редакциянең адресы: 420066,**
**Казан, Декабристлар ур., 2.**

Белешмалар өчен телефоннар:
(843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле

16+

# Уйна да, уйла да!




Ринат АБЗАЛОВ төзеде




**1.** Яшәү минимумын күтәрү өчен нишләргә кирәк?

**2.** Җәннәт белән тәмугның төп аермасы?

**3.** Нәрсә ул инфляция?

**4.** Нәрсә ул наркоз?

**5.** Ир кешенең өйдә ярдәме?

**6.** Ваемсызлыкны үлчәү берәмлеге?

**7.** Хатынны ничек табарга?

## ҖАВАПЛАР

1. Биранәнә тыгылган кайберәүләрнең максимумнарын киметергә. 2. Җәннәттә бөтенләй эшләмисең, ә тәмугта эш кайнап тора. 3. «Эшче хезмәте» товарыннан башка, бөтен товарларның бәясен күтәрү. 4. Пациент киңәшләреннән котылу чарасы. 5. Хатыны идән себергәндә аякларны күтәреп утыру. 6. "Барыбер түгелмени?" дию. 7. Акчаң булса, хатыннар үзләре таба.

**Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде**

**Ч**аянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 7 нче санындагы чаянвордның тикшерү сүзе – **«ТАШЛАП КИТМӘ»**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

**Г. БАҺАВЕТДИНОВ** (Чаллы),
**Т. САЛИХОВ** (Казан),
**С. ШӘЙХУЛЛИН** (Казан),
**Р. ШӘРИФУЛЛИН** (Әлмәт).

Җиңүчебез – Чаллыдан **Гали БАҺАВЕТДИНОВ!**






Василий АЛЕКСАНДРОВ


Виктор ФЁДОРОВ


Валерий ТАРАСЕНКО


Максим СМАГИН



Константин ЧАХИРОВ



